КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 30 декабрь г.Казань № 1465

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схемага үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схеманы раслау турында» 2018 ел, 13 март, 149 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 14 май, 391 нче; 2020 ел, 21 май, 414 нче, 2021 ел, 19 октябрь, 985 нче, 2022 ел, 09 июль, 661 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында калдыклар белән өлкәсендә территориаль схемага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

9 бүлектә:

9.5 бүлекчәдә:

җиденче абзацта «ИТС 15-2016 Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру (термик ысул белән зарарсызландырудан тыш (калдыкларны яндыру))» сүзләрен «ИТС 15-2021. «Калдыкларны утильләштерү һәм зарарсызландыру (термик ысуллардан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «ИТС 9-2015 «Калдыкларны термик ысул белән зарарсызландыру (калдыкларны яндыру)» сүзләрен «ИТС 9-2020 «Калдыкларны термик ысуллар белән утильләштерү һәм зарарсызландыру» сүзләренә алмаштырырга;

9.6 бүлекчәнең унҗиденче абзацында «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 бүлектә:

10.2.3.1 бүлекчәнең өченче абзацында "Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Калдыкларны термик ысул белән зарарсызландыру (калдыкларны яндыру)» (ИТС 9-2015, Мәскәү, НТД бюросы, 2015)» сүзләрен «Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Калдыкларны термик ысуллар белән утильләштерү һәм зарарсызландыру» (ИТС-2020, Мәскәү, НТД бюросы, 2020)» сүзләренә алмаштырырга;

10.4 бүлекчәдә:

җиденче абзацта «башкарма хакимият органы» сүзләрен «башкарма орган» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга;

унынчы абзацта «башкарма хакимият органнары» сүзләрен «башкарма органнар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин